РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
КУКМОРСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
СОВЕТ ЯДЫГЕРЬСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
422124, РТ, Кукморский район,
с. Ядыгерь, ул.Ленина д.28а

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЯДЕГӘР АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
422124, РТ, Кукмара районы,
Ядегәр авылы, Ленин урамы, 28а йорт

тел.: (8 84364) 35-5-88, факс (8 84364) 35-5-88; e-mail:Yad.Kuk@tatar.ru

КАРАР

22 март, 2024 ел №8

Кукмара муниципаль районы Ядегәр авыл җирлегенең Тарлау авылы торак пунктында «Кукмара муниципаль районы Ядегәр авыл җирлегенең Тарлау торак пунктында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 30 ноябрендәге 1 номерлы Тарлау авылы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрүне билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Ядегәр авыл җирлеге Уставы нигезендә, Ядегәр авыл җирлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

РЕШИЛ:

1. 2024 елның 7 апреленә 09 сәгать 00 минутка «Кукмара муниципаль районы Ядегәр авыл җирлегенең Тарлау торак пунктында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 30 ноябрендәге 1 номерлы Тарлау авылы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Тарлау авылы, Г.Ибраһим урамы, 11а адресында урнашкан Тарлау авылы мәчете бинасында уздырырга.

2. 2024 елның 7 апреленә 10 сәгать 00 минутка «Кукмара муниципаль районы Ядегәр авыл җирлегенең Тарлау торак пунктында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 30 ноябрендәге 1 номерлы Тарлау авылы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Тарлау авылы, Г.Ибраһим урамы, 11а адресында урнашкан Тарлау авылы мәчете бинасында уздырырга.

3. Гражданнар җыенын үткәрү өчен торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген территориаль билге буенча (урамнар буенча) бүләргә.

4. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:
«Сез Кукмара муниципаль районы Тарлау авыл җирлегенең Тарлау авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында 2023 елның 30 ноябрендәге 1 номерлы карарына түбәндәге мәсьәлә буенча үзгәрешләр кертүгә ризамы: «Сез 2024 елда Кукмара муниципаль районының Ядегәр авыл җирлеге Тарлау авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидларыннан; көндезге уку формасы буенча укучы укучылар һәм студентлардан (курсантлардан); 18 яшькә кадәрге бала тәрбияләүче ялгыз аналардан; 80 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, 500 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:
- Тарлау авылындагы юлларны кышкы-җәйге чорда карап тоту һәм проект-смета документларын эшләү, килешү буенча эш өчен түләү;
- Тарлау авылының Пушкин урамы юлларын вак таш салып төзү һәм ремонтлау, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, килешү буенча түләү;
- Тарлау авылына энергия саклаучы лампалар, светодиодлы яктырткычлар, махсус җиһазлар сатып алу, урнаштыру, ремонтлау һәм карап тоту;
- чишмәләрне төзекләндерү, карап тоту, проект-смета документлары, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, материал сатып алу, ташу һәм чишмәне төзекләндерү һәм тоту буенча башка эш төрләре;
- су башнясы өчен насос сатып алу һәм урнаштыру, су белән тәэмин итү трассасын төзү һәм ремонтлау, һәм проект-смета документларын эшләү, килешү буенча эш өчен түләү;
- «Сабантуй» уздыру урыны территориясен төзекләндерү, һәм проект-смета документларын эшләү, килешү буенча эш өчен түләү;
- Тарлау авылы юлларына асфальт җәю, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру; һәм экспертиза үткәрү, килешү буенча түләү;
- Тарлау авылы зиратларын карап тоту, материаллар, кораллар сатып алу һәм коймалау, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, килешү буенча түләү;
- Тарлау авылы мәчете каршында машина кую урыны төзү, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру; һәм экспертиза үткәрү, килешү буенча түләү;
- халыкның күпләп ял итү урыннарын төзү, ремонтлау һәм аларга якын территорияне төзекләндерү, һәм проект-смета документларын эшләү, килешү буенча эш өчен түләү?

2023 елның 30 ноябрендәге 1 номерлы карарында күрсәтелгән эш төрләрен үзгәртү өлешендә түбәндәге эшләр белән:

- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту (Тарлау авылындагы юлларны кышкы-җәйге тоту һәм проект-смета документациясен эшләү, килешү буенча түләү);

(Пушкин урамы, Тарлау авылы буенча вак таш белән капланган юллар төзү һәм ремонтлау, проект-смета документациясен эшләү һәм технадзорны гамәлгә ашыру, килешү буенча түләү);

(Тарлау авылы урамнарына асфальт салу, проект-смета документациясен эшләү, технадзорны гамәлгә ашыру һәм экспертиза үткәрү, килешү буенча түләү);

- тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны (энергия саклаучы лампаларны, светодиодлы яктырткычларны, Тарлау авылында махсус җиһазларны сатып алу, урнаштыру, ремонтлау һәм тоту)ремонтлау;

- җир асты суларының табигый чыгу урыннарын төзекләндерү (чишмәләр) (төзекләндерү, чишмәләрне тоту, проект-смета документациясе, технадзорны гамәлгә ашыру, материал сатып алу, ташу һәм чишмәләрне төзекләндерү һәм тоту буенча башка эш төрләре);

- су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу системаларын, су күтәрү манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (су күтәрү манарасы өчен насос сатып алу һәм урнаштыру, су белән тәэмин итү трассасын төзү һәм ремонтлау проект-смета документациясен эшләү, килешү буенча түләү);

- торак пункт территориясен төзекләндерү ("Сабантуй" уздыру урыннарын төзекләндерү, проект-смета документларын эшләү, килешү буенча түләү);

(Тарлау авылы мәчете каршында парковка урыны төзү, проект-смета документациясен эшләү, технадзорны гамәлгә ашыру һәм экспертиза үткәрү, килешү буенча түләү);

(халыкның күпләп ял итү урыннарын төзү, ремонтлау һәм аларга якын территорияне төзекләндерү, проект-смета документациясен эшләү, килешү буенча түләү);

- традицион Күмү урыннарын ремонтлау, коймалар төзү, төзекләндерү (Тарлау авылындагы зиратларны саклау, материаллар, кораллар сатып алу һәм коймаларны урнаштыру, проект-смета документациясен эшләү һәм технадзорны гамәлгә ашыру, килешү буенча түләү);

«РИЗА» «КАРШЫ»

*5.Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Янил* авыл җирлеге Уставында билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарырга, шулай ук аны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

Ядегәр авыл җирлеге башлыгы: А.Н.Фәйзуллин